ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.05.2023 Олы Кайбыч ав. № 183

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 20 декабрендәге 524 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 480-ФЗ номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 20 декабрендәге 524 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 2.9 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 3-11 пунктларында каралган әлеге маршрутлар турындагы белешмәләрне әлеге реестрларда күрсәтелгән маршрутлар турындагы белешмәләр кертелгән көннән башлап, әлеге маршрутлар турында белешмәләрне даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршрутлары

реестрларына кертү көнемә ярашлы рәвештә билгеләнгән яисә үзгәртелгән дип санала.»;

2 нче кушымтаның 2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрына түбәндәге белешмәләр кертелергә тиеш:

1) тиешле реестрда даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының теркәү номеры;

2) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән тәртип номеры;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның башлангыч тукталыш пунктының һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның соңгы тукталыш пунктының исемнәре йә чикләрендә башлангыч тукталыш пункты һәм әлеге маршрут буенча соңгы тукталыш пункты урнашкан җирлекләрнең исемнәре рәвешендә әлеге маршрут исеме;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча арадаш тукталыш пунктлары исемнәре йә чикләрендә арадаш тукталыш пунктлары урнашкан җирлекләр исемнәре;

5) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте күздә тотыла торган урамнар, автомобиль юллары исемнәре;

6) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты озынлыгы;

7) пассажирлар утырту һәм төшерү тәртибе (билгеләнгән тукталыш пунктларында гына яисә, әгәр бу 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон белән тыелмаса, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча теләсә кайсы юл хәрәкәте кагыйдәләрендә тыелмаган урында);

8) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төре;

9) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутын билгеләү яисә үзгәртү турында карар белән, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрутын билгеләү яисә үзгәртү хакында муниципаль контрактта һәм (яисә) ачык конкурста катнашучы тарафыннан бирелгән ачык конкурста катнашуга гариза белән каралган транспорт чараларына характеристикалар (транспорт чаралары төрләре, транспорт чараларының класслары, транспорт чараларының экологик характеристикалары, транспорт чараларыннан максималь файдалану срогы, пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның сыйфатына йогынты ясый торган транспорт чараларына характеристикалар);

10) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча файдалану рөхсәт ителә торган һәр класслы транспорт чараларының максималь саны;

11) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлау датасы;

12) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы салым түләүченең исеме, урнашу урыны (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме һәм, әгәр булса, атасының исеме, яшәү урыны (индивидуаль эшмәкәр өчен), идентификация номеры;

13) Татарстан Республикасы законында каралган башка белешмәләр (даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларына карата).»;

3 нче кушымтаны кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023е ___________ _______ номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары исемлегеннән файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктлары исемлеге

| № т/б | Маршрут исеме | Башлангыч тукталыш пункты | Соңгы тукталыш пункты |
|---|---|---|---|
| 1 | Олы Кайбыч – Надеждино - Олы Кайбыч | Олы Кайбыч, Гарәфетдинов проспекты | Надеждино, Үзәк ур. |
| 2 | Олы Кайбыч – Салтыган - Олы Кайбыч | Олы Кайбыч, Гарәфетдинов проспекты | Салтыган, Үзәк ур. |
| 3 | Олы Кайбыч - Кече Мәми - Олы Кайбыч | Олы Кайбыч, Гарәфетдинов проспекты | Кече Мәми, Яшьләр ур. |
| 4 | Олы Кайбыч-Камыллы | Олы Кайбыч, Гарәфетдинов проспекты | Камыллы, Үзәк ур. |
| 5 | Олы Кайбыч - Шүширмә - Олы Кайбыч | Олы Кайбыч, Гарәфетдинов проспекты | Шүширмә, Гагарин ур. |